ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2025 Мөслим ав. № 56

Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» 2024 елның 12 декабрендәге 547 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәт составына керүче биналарны карап тоту буенча эшләрнең минималь исемлеге һәм «Мөслим» ИК ҖЧҖнең чыгымнарны калькуляцияләү турында 2025 елның 27 гыйнварындагы, №04-04/1353 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» 2024 елның 12 декабрендәге 547 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, 1 нче кушымтага түбәндәге юллар өстәргә:

- №8 «Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру», хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен тариф (рубльләрдә), НДСны исәпкә алып - аена торак урынның гомуми мәйданының кв. метры өчен 1,10;
- №9 «Дератизация (дезинсекция)», хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен тариф (сумнарда), НДСны исәпкә алып - аена торак урынның гомуми мәйданының кв. метры өчен 0,20;
- №10 «Йорт эчендәге газ җиһазларын техник диагностикалау» (түләү диагностика үткәрү срогы башланганчы 12 ай дәвамында башкарыла), хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен тариф (рубльләрдә), НДС исәпкә алып - аена торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры өчен 0,22.

2. Әлеге үзгәрешләр 01.01.2025 елдан бирле гамәлдә.
3. Әлеге карарны «Авыл Утлары» район газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И. Ф Салихҗанов**